КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 46

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2012 ел, 11 февраль, 98 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2012 ел, 11 февраль, 98 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 гыйнвар, 21 нче; 2015 ел, 10 октябрь, 759 нчы; 2016 ел, 9 апрель, 211 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1068 нче; 2018 ел, 17 гыйнвар, 16 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 8 нче, 2019 ел, 30 декабрь, 1250 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан А.Н.Кудрявцеваны чыгарырга;

коллегия составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе Шәфигуллин Лотфулла Нурислам улын кертергә (килештерү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин